КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 декабрь г.Казань № 1374

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында Авыл территорияләрен комплекслы үстерү Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында 2020 ел, 14 май, 387 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә квалификацияле белгечләрне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында Авыл территорияләрен комплекслы үстерү Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру турында 2020 ел, 14 май, 387 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 741 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1049 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1165 нче, 2021 ел, 11 май, 325 нче, 2021 ел, 31 май, 416 нчы, 2021 ел, 12 июнь, 446 нчы, 2022 ел, 3 июнь, 514 нче, 2022 ел, 11 июнь, 550 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә квалификацияле белгечләрне тәэмин итүдә ярдәм күрсәтүгә субсидияләр бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацында Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнары сүзләрен Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) Бюджет бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.;

5 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);;

8 пунктның уникенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

12 пунктның е пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

е) субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе).;

19 пунктның а  һәм б пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) әлеге Кагыйдәләрнең 2.1 пунктындагы а пунктчасында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирелгәндә, - Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгариф оешмаларында максатчан уку турында шартнамәләр һәм шартнамәләр буенча белем алучылар саны һәм мөрәҗәгать итүчеләрне агымдагы финанс елның 31 декабренә торышы буенча   башка мәгариф оешмаларында белем алучылар саны;

б) әлеге Кагыйдәләрнең 2.1 пунктындагы б пунктчасында күрсәтелгән максатларга субсидияләр бирелгәндә, - Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы мәгариф оешмаларында укучы һәм практика узу, шул исәптән җитештерү практикасы узу өчен җәлеп ителгән башка белем бирү оешмаларында белем алучылар саны һәм агымдагы финанс елның 31 декабренә торышы буенча белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәсендә субсидия бирү елында яисә субсидия бирү елында кимендә алты ай хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы яисә субсидияләр бирү елында белем алучылар саны..

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин